# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**№1** **16.11.2023 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Микулино авыл җирлеге
Александровка авылында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле узидарә оештырунын гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Уставы нигезендә 2023 елның 16 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гаражданнар жыенының йомгаклау протоколы төзелде:
Сез, 2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге Александровка торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында белем алучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән карата 350 сум күләмендә, мобилизация буенча чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларына, 2 төркем инвалидлар өчен 175 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсъәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тотуга ризамы:

- Александровка авылында юлларны кардан чистарту.

РИЗА КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә яраклы рәвештә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 13 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 13 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында катнашкан 13 кеше "РИЗА" позициясе өчен тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Азнакай муниципаль районы Микулино авыл жирлеге Александровка авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенынын нәтиҗәләре – гамәлдә дөрес дип танырга.
2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:
Сез, 2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл җирлеге Александровка торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында белем алучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр

балигъ булган кешедән карата 350 сум күләмендә, мобилизация буенча чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларына, 2 төркем инвалидлар өчен 175 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсъәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тотуга ризамы:

- Александровка авылында юлларны кардан чистарту.

3. Әлеге карарны Микулино авыл җирлегенең торак пунктының түбәндәге адрес буенча урнашкан: Микулино авылы, Александровка авылы, Нефтяник урамы,1, мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Микулино авыл жирлеге башлыгына жибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Микулино авыл җирлеге Башлыгы: И.А.Такиулин